СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**29.11.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 171**

Зеленодольск шәһәре Советының «Зеленодольск шәһәре территориясендә 2020 елның 1 гыйнварыннан җир салымы ставкалары, түләү тәртибе турында» 2019 елның 13 ноябрендәге 264 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Зеленодольск шәһәре Советының 2020 елның 18 декабрендәге 13 номерлы, 2022 елның 26 августындагы 88 номерлы, 2023 елның 23 ноябрендәге 136 номерлы карарындагы үзгәрешләрне исәпкә алып)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон (29.10.2024 ел редакциясендә), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск шәһәре Советының «Зеленодольск шәһәре территориясендә 2020 елның 1 гыйнварыннан җир салымы ставкалары, түләү тәртибе турында» 2019 елның 13 ноябрендәге 264 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Зеленодольск шәһәре Советының 2020 елның 18 декабрендәге 13 номерлы, 2022 елның 26 августындагы 88 номерлы, 2023 елның 23 ноябрендәге 136 номерлы карарындагы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.4 пунктындагы өченче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«- торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), әлеге абзацта күрсәтелгән эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш, һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан

арткан җир кишәрлекләреннән тыш;»;

1.2. 1.4 пунктындагы дүртенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

- «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен, шулай ук гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләрендә сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган , әлеге абзацта күрсәтелгән һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш;».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач, үз көченә керә

3. Әлеге карарны 2024 елның 1 декабренә кадәр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми Порталында , Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшмәкәрлекне үстерү буенча даими комиссия рәисенә йөкләргә.

**Зеленодольск шәһәре Мэры,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**